# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

## Татарстан Республикасы халык депутаты статусы турында Татарстан Республикасының аерым законнарына үзгәрешләр һәм өстәмә кертү хакында

1 статья. «Татарстан Республикасы халык депутаты статусы турында» Татарстан Республикасы Законына (1996 елның 30 маендагы 611 номерлы Татарстан Республикасы Законы редакңиясендә) (Татарстан Югары Советы Җыелма басмасы, 1992, №1; Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1996, № 6) түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәне кертергә:

1. 22 статьяның эчтәлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«22 статья. Татарстан Республикасы халык депутатының кагылгысызлыгы

Татарстан Республикасы халык депутаты барлык вәкаләтләре чорына федераль закон нигезендә кагылгысызлыкка ия.Ул, җинаять урынында тоткарлау очракларыннан гайре, шулай ук башка кешеләрнең иминлеген тәэмин итү өчен федераль законда каралган очраклардан тыш, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы ризалыгыннан башка, җинаять җаваплылыгына яисә суд тәртибендә билгеләнә торган административ җаваплылыкка тартылмый, тоткарланмый, кулга алынмый, аңа тентү ясалмый яисә ул сорау алуга, шәхси яктан тикшерүгә җәлеп ителми.

Татарстан Республикасы халык депутатының кагылгысызлыгы аның биләгән торагына һәм хезмәт урынына, багажына, шәхси һәм хезмәт транспорт чараларына, хатларына, файдалана торган элемтә чараларына, шулай ук документларына да карый.

Әлеге статьяның 1 һәм 2 өлешләрендә күрсәтелгән чикләүләр Татарстан Республикасы халык депутатының шәхескә каршы җинаятьләренә бәйле гамәлләренә, шулай ук Татарстан Республикасы халык

депутатының үз вәкаләтләрен башкаруга бәйле булмаган бүтән гамәлләренә кагылмый.

Татарстан Республикасы халык депутатының үз вәкаләтләрен башкаруга бәйле булмаган гамәлләренә карата җинаять җаваплылыгын яисә суд тәртибендә билгеләнә торган административ җаваплылыкны күздә тотучы эшләр кузгатылган очракта, алдан сорап белешү, алдан тикшерү яисә административ хокук бозулар буенча эшләр башкару тәмамлангач, мондый эш федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы ризалыгыннан башка судка тапшырыла алмый. Татарстан Республикасы халык депутатына карата тикшерү эшләре һәм административ хокук бозулар буенча эшләр башкару тәртибе Татарстан Республикасы Прокурорының турыдан-туры үз күзәтүе астында гамәлгә ашырыла.

Татарстан Республикасы халык депутаты үзенең әйткән фикере, тавыш биргәндә белдергән позициясе һәм Татарстан Республикасы халык депутаты статусына туры килә торган бүтән гамәлләре өчен, шул исәптән аның вәкаләтләр чоры узгач та, җинаять җаваплылыгына яисә административ җаваплылыкка тартыла алмый. Әлеге нигезләмә Татарстан Республикасы халык депутатының федераль законда җаваплылык каралган ачыктан-ачык мәсхәрәләүләре, яла ягулары яисә бүтән хокук бозулары очракларына кагылмый.».

2. 23 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«23 статья. Татарстан Республикасы халык депутатын кагылгысызлыктан мәхрүм итү өчен Дәүләт Советы ризалыгын алу тәртибе

Татарстан Республикасы халык депутатын кагылгысызлыктан мәхрүм итү турындагы мәсьәлә Татарстан Республикасы Прокуроры тәкъдиме буенча хәл ителә.

Татарстан Республикасы халык депутатын, җинаять урынында тоткарлау очракларыннан гайре, шулай ук башка кешеләрнең иминлеген тәэмин итү өчен федераль законда каралган очраклардан тыш, җинаять җаваплылыгына яисә суд тәртибендә билгеләнә торган административ җаваплылыкка тартуга, аны тоткарлауга, кулга алуга, аңа тентү ясауга яисә сорау алуга, шулай ук шәхсән тикшерүгә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы ризалыгын алу өчен Татарстан Республикасы Прокуроры Татарстан Республикасы Дәүләт Советына тәкъдим кертә. Мондый ризалык алу

127

Татарстан Республикасы халык депутатының үз вәкаләтләрен башкаруга бәйле гамәлләренә карата күздә тотыла.

Татарстан Республикасы Прокуроры тәкъдиме әлеге Законның 22 статьясындагы 4 өлешендә каралган очракларда эшне судка тапшыруга Татарстан Республикасы Дәүләт Советы ризалыгын алу өчен дә кертелә.

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Регламентында билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы Прокуроры тәкъдимен карый һәм тәкъдимне алган көннән ундүрт көннән дә соңга калмыйча аның буенча дәлилләнгән карар кабул итә.

Татарстан Республикасы халык депутатын кагылгысызлыктан мәхрүм итү турындагы мәсьәләне караганда үзенә карата тәкъдим кертелгән Татарстан Республикасы халык депутаты катнашырга хокуклы.

3. Законга түбәндәге эчтәлекле $23^1$ статья өстәргә:

«$23^1$ статья. Татарстан Республикасы халык депутатының шаһитлык күрсәткечләре бирүдән баш тарту хокукы

Татарстан Республикасы халык депутаты үз вәкаләтләрен башкаруга бәйле рәвештә аңа мәгълүм булган хәлләр турында граждан яисә җинаять эше буенча шаһитлык күрсәткечләре бирүдән федераль закон нигезендә баш тартырга хокуклы.».

2 статья. «Татарстан Республикасы халык депутатлары статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Законының (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1996, №6) 2 статьясындагы икенче җөмләсен төшереп калдырырга.

3 статья. Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты

М.Шәймиев

Казан шәһәре,
2001 елның 11 мае
№ 798